СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский
муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арч
муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

## КАРАРЫ

« 22 » август, 2019 ел № 83

### “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “ Иске Чуриле” муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданна[р] җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында " Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзида[рә] оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы федера[ль] законның 25.1 статьясын, 2004 елның 27июлендәге “Татарст[ан] Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарст[ан] Республикасы законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Ар[ча] муниципаль районы “Иске Чуриле” муниципаль берәмлеге Уставы статьяларь[н] тормышка ашыру максатында Иске Чуриле Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чури[ле] Советының 2018 елның 22 нче октябрдәге “Татарстан Республикасы Ар[ча] муниципаль районы “Иске Чуриле” муниципаль берәмлеге составына керү[че] торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында " [...] 61 нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр[не] кертергә:

1)1.6. пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа җирлек төз[елү] турында халык инициативасын алга сөрү максатларында, шулай ук яңа төзелг[ән] җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия булган халык саны 300 кешедән артмас[а,] яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгел[әү] мәсьәләсе буенча»;

2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрне[ң] яртысыннан артыгы катнашканда хокукка ия. Торак пунктта әлеге тор[ак] пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысынн[ан] артыгы бер үк вакытта бергә җыелу мөмкинлеге булмаса, әлеге торак пун[кт] кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этапла[п]

гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Арча муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җирлек башлыгы урынбасары Р.Х.Гарифуллин